**Республика Татарстан**
**Карашай-Сакловское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге**

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

24 сентябрь 2020 ел № 7

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата түләү күләмен арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 06 августындагы 658 номерлы карары, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Ул Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 19 апрелендәге 2 номерлы карары белән расланган Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Интернет челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Карашай-Саклау авыл җирлеге
Советы Рәисе В.В.Хосниева